# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

2001-2004 елларга кече эшкуарлыкны үстерү буенча
Татарстан Республикасы дәүләт комплекслы
программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 10 һәм 89 статьялары нигезендә Кече эшкуарлыкны үстерү буенча Татарстан Республикасының дәүләт комплекслы программасы Татарстан Республикасының дәүләт икътисадый сәясәтенең иң мөһим элементларыннан берсе булып тора.

1 статья. 2001-2004 елларга кече эшкуарлыкны үстерү буенча дәүләт комплекслы программасын расларга (кушымта итеп бирелә).

2 статья. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты югарыда аталган программаны гамәлгә ашыру өчен түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

- программада каралган норматив хокукый актларны әзерләргә;
- кирәкле оештыру-техник чаралар әзерләргә;
- тармак принцибы буенча үсешнең өстенлекле юнәлешләрен эшләргә;
- 2002-2004 елларга Татарстан Республикасының Республика бюджеты турында Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләгәндә акчаларны күз алдында тотарга;
- Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәга палатасы һәм эшкуарлар берлекләре белән берлектә өстенлекле тармаклар, шулай ук республика районнары һәм шәһәрләре кысасында мониторингны тәэмин итү өчен координация советы төзергә.

3 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 28 феврале
№ 679

2001 елның 28 февралендәге
Татарстан Республикасы Законына
кушымта № 679

**2001-2004 елларга кече эшкуарлыкны үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт комплекслы программасы[*]**

# ПАСПОРТЫ

**Программаның исеме**

2001-2004 елларга кече эшкуарлыкны үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт комплекслы программасы

**Программаны әзерләү өчен нигез**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең 2000 елның 8 сентябрендәге 216 нчы күрсәтмәсе

**Программаны әзерләүчеләр**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
Татарстан Республикасының Икътисад һәм сәнәга министрлыгы
Татарстан Республикасының Икътисад һәм сәнәга министрлыгы каршындагы Кече эшкуарлыкка ярдәм һәм аны үстерү департаменты
Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәга палатасы

**Программаны үтәүчеләр**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Татарстан Республикасының министрлыклары, ведомстволары
Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләре администрацияләре
Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәга палатасы
Иҗтимагый берләшмәләр

**Программаның максаты һәм бурычлары**

Алга киткән илләрнең икътисады эре һәм кече бизнесның оптималь чагыштырмасы белән характерлана. Кече бизнес җәмгыятьнең социаль тотрыклылыгын тәэмин итәрлек урта сыйныф булуны аңлата.

<u>Программаның максаты:</u> урта сыйныфны барлыкка китерү, базар хуҗалыгының тотрыклылыгын тәэмин итү. Моның өчен түбәндәгеләрне тәэмин итәргә кирәк:

---
[*] Алга таба текстта «Программа» атамасы кулланылачак.

1. Дәүләт ярдәме гамәлләренең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыру;

2. Кече эшкуарлык үсеше юлында административ каршылыкларны бетерү;

3. Кече эшкуарлыкны хуплауның, кече эшкуарлыкның өстенлекле юнәлешләрен финанслау өчен акчаларны туплауның, кече эшкуарлыкны финанслау механизмнарын гомуми кредит-финанс системасы белән интеграцияләүнең прогрессив финанс технологияләрен әзерләү һәм гамәлгә кертү;

4. Яңа эш урыннары булдыру;

5. Импортны алыштырырлык продукция җитештерү өчен шартлар тудыру;

6. Фәнни-җитештерү эшчәнлек өлкәсендә кече эшкуарлыкны үстерү;

7. Дәүләт заказын үтәү өчен кече предприятиеләрне җәлеп итү;

8. Кече эшкуарлыкны хуплау инфраструктурасы кысаларында кече предприятиеләргә адреслы методик, мәгълүмати, консультатив, мәгърифәти һәм хокукый ярдәм күрсәтү;

9. Кече предприятиеләрнең тышкы икътисадый эшчәнлеген һәм төбәкара хезмәттәшлеген үстерү, кече эшкуарлык секторына чит ил инвестицияләрен җәлеп итү өчен шартлар тудыру.

**Программаның төп юнәлешләре:**

1. Кече эшкуарлыкны закон чыгарып һәм норматив хокукый яктан тәэмин итү;

2. Кече эшкуарлыкны хуплауның прогрессив финанс технологияләрен үстерү;

3. Кече эшкуарлыкны үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыру;

4. Кече эшкуарлыкны тәэмин итүнең мәгълүмати системаларыннан һәм кече эшкуарлыкның булдырылган инфрастуктурасыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

5. Кече эшкуарлыкны фәнни-методик һәм кадрлар ягыннан тәэмин итү;

6. Кече эшкуарлык проблемаларын һәм аларны хәл итү юлларын яктырту, аларны тикшерү, эшкуарлык эшчәнлеген пропагандалау, эшкуарлыкка мәгълүмати ярдәм күрсәтү өлкәсендә массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү;

7. Кече эшкуарлык өлкәсендә төбәкара һәм халыкара хезмәттәшлек.

**Программаны гамәлгә ашыруның көтеләчәк нәтиҗәләре**

1. Кече предприятиеләрнең санын ел саен 600-1000 берәмлеккә арттырганда, 2004 ел азагына аларның саны 20 мең берәмлектән артып китәр дип фаразларга мөмкин;

2. Программа чараларын үтәү гамәлдәге кече предприятиеләрне саклап калу һәм яңаларын булдыру өчен шартлар тудырачак, һәм бу кече эшкуарлык өлкәсендәге эш урыннары санын 40 меңгә арттырырга мөмкинлек бирәчәк;

3. Программа гамәлләрен ахыргача үтәгәндә тулаем эчке продуктка кече эшкуарлыкның гомуми өлеше 15 процентка кадәр артачак.

**Программаны финанслау чыганаклары**

Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар, Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме күрсәтүнең республика фонды, бюджеттан тыш фондлар акчалары, эшкуарларның үз акчалары, җәлеп ителгән инвестицияләр.

## 2001-2004 елларга кече эшкуарлыкны үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт комплекслы программасы

### I. Проблеманың эчтәлеге һәм аны хәл итү зарурлыгы

Кече эшкуарлык үсешенең хәзерге вакытта ирешелгән дәрәҗәсе яңа эш урыннарын тизрәк барлыкка китерү, базарда ихтыяҗны һәм тәкъдимнәрне җанландыру, халыкның икътисадый актив өлешендә хосусый эшкуарлык инициативасы исәбеннән мөстәкыйль керем чыганакларын барлыкка китерү, барлык дәрәҗәдәге бюджетларның чыгымнарына социаль йөкләнешләрне киметү өчен җитәрлек түгел әле.

Соңгы елларда кече предприятиеләрнең тармак структурасы күзгә күренерлек үзгәрмәде. Эшчәнлекнең җитештерүгә карамаган өлкәсе (иң беренче чиратта сәүдә һәм җәмәгать туклануы) җитештерү өлкәсенә караганда кызыктырырлык булып кала. 1998 елның августыннан соң кече предприятиеләрнең 25 тән алып 35 процентына кадәре чынбарлыкта үз эшчәнлекләрен туктаттылар. Калганнары үз бизнеслары масштабларын персонал санын һәм хезмәт өчен түләүне киметү исәбенә саклап калуга көчтеләр.

Кече эшкуарлык субъектлары эшчәнлеге күп кенә очракларда башкарма хакимият органнары гамәлләренә бәйле. Дәүләт ярдәменең махсус гамәлләреннән башка кече эшкуарлыкның үсеше мөмкин түгел. Кече эшкуарлыкка дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтү макроикътисадый шартлар белән тоткарлана.

Программаның төп гамәлләре, барыннан да элек, кече эшкуарлык үсешен тоткарлаучы проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелә, шулардан:

- республиканың тотрыклы норматив хокукый базасы булмау;
- салым салу системасының камил булмавы;
- кече эшкуарлыкны бюджеттан финанслауның тотрыксызлыгы;

- кече предприятиеләргә финанс-кредит ярдәме һәм аларның тәвәкәллеген иминләштерү механизмнарының үсеш алмавы;
- үзфинанслау (кредит берлекләре, үзара иминләштерү җәмгыятьләре һәм башкалар) механизмнарының булмавы;
- кече предприятиеләрнең реструктуризацияләнүче предприятиеләр җитештерү көчләренә һәм мөлкәтенә ия булуын чикләү;
- эшкуарларны ышанычлы соңиаль яклау һәм иминлек булмау;
- кече бизнесның базар һәм дәүләт структуралары белән үзара хезмәттәшлегенең оештыру проблемалары;
- кече эшкуарлык үсеше юлында административ каршылыклар булу.

## II. Куелган бурычларны хәл итү юнәлешләре

Программа бурычларының һәрберсе башкалары белән үзара нык бәйләнгән, алары исә, кече эшкуарлыкка дәүләт ярдәменең функцияләренә карап, түбәндәге юнәлешләр буенча хәл ителәләр:

1. Кече эшкуарлыкны норматив хокукый яктан тәэмин итү;
2. Финанс технологияләрен үстерү;
3. Кече эшкуарлык үсешенең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыру;
4. Кече эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасыннан һәм мәгълүмати системалардан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;
5. Кече эшкуарлыкны фәнни-методик һәм кадрлар ягыннан тәэмин итү;
6. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек һәм эшкуарлык эшчәнлеген пропагандалау;
7. Кече эшкуарлык өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлек.

Закон чыгаруны камилләштерү тематик блоклар буенча алып барылырга тиеш: базарга чыгу (предприятиеләрне теркәү) һәм базардан китү (предприятиеләрне ликвидацияләү) проблемалары; базарда контроль (лицензияләү, сертификацияләү, тикшерү) һ.б.

Кече предприятиеләргә салым салуның камилсезлегеннән килеп чыккан проблемаларны хәл итү өчен аларга ташламалы салым салу турында тәкъдимнәр әзерләргә кирәк.

Кече предприятиеләрне финанслау проблемаларын хәл итү өчен финанс системасының барлык участокларындагы җаваплылыкның механизмнарын һәм өлкәләрен төгәл билгеләү зарур.

Эшкуарларны кредитлауның төгәл регламентланган системасы булмау шартларында, шулай ук финанс мөмкинлекләренең чикләнгәнлегенә бәйле рәвештә кредитлар һәм заемнар буенча, финанс гарантияләрен һәм ипотека кредитлавын кулланган механизмнар нигезендә кече предприятиеләр белән эшләү буенча гарантияләр бирү хокукына ия булган структуралар өчен норматив-методик тәкъдимнәр әзерләү иң зур әһәмият ала.

Кече предприятиеләрнең реструктуризацияләнүче предприятиеләр мөлкәтенә ия булу проблемаларын хәл иткәндә кече предприятиеләрне сәүдәләргә (торгларга) мәҗбүри җәлеп итү нормаларын закон белән беркетергә, үзләренең икътисадый һәм җитештерү күрсәткечләре буенча дәүләт иҗтыяҗлары өчен продукция бирүгә заказлар урнаштыруда катнашырга сәләтле кече предприятиеләр исемлеген булдырырга кирәк.

Кече предприятиеләр хезмәткәрләре мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү өчен кече предприятиеләр эшчәнлегендә хокукый мөнәсәбәтләр үзенчәлеген исәпкә алырлык документлар әзерләү зарур.

**Кече эшкуарлык үсешенә комачаулаучы административ каршылыкларны бетерү буенча тәкъдимнәр әзерләү кысаларында түбәндәгеләрне күз алдында тотарга кирәк:**

- контроль функцияләрне башкаруга рөхсәт алган һәм кече эшкуарлык субъектлары эшчәнлеген планлы һәм башка төрле тикшерүне башкаручы оешмаларның тулы исемлеген төзү;
- контроль ясаучы органнарның исемлеген кыскарту, вәкаләтләрнең кабатлануын булдырмыйча, аларның компетенцияләрен чикләү;
- тикшерүләрне уздыру тәртибен билгеләүче тиешле норматив хокукый актлар әзерләү;
- тикшерүләр вакытында тутырылучы документларның рәвешләрен унификацияләү; ведомстволар инструкцияләре, санкцияләр; штрафларның шкаласын әзерләү;
- тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру;
- тикшерү нәтиҗәләренә судлардан тыш шикаять белдерү буенча предприятиеләрнең хокукларын һәм мондый шикаять бирүнең процедурасын билгеләү.

Кече эшкуарлык вәкилләре исәпкә алу, бизнес-планлаштыру, маркетинг, финанс анализы, хокукый культура тәҗрибәсенә тиешенчә ия булмаганга күрә, кече эшкуарлык субъектлары эшчәнлеген методик тәэмин итүне көчәйтергә кирәк.

**Кече эшкуарлыкка дәүләт ярдәменең сыгылмалы системасын тәэмин итүнең беренче нәүбәттәге гамәлләре:**

- кече эшкуарлыкка ярдәм итү дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм аны гамәлгә ашырганда хәбәрдарлык;
- дәүләт ярдәменең конкрет гамәлләренең эчтәлеге турында тулы һәм хәбәрдар мәгълүмат булу, акча бүлүнең ачык процедураларын билгеләү, кече эшкуарлыкка ярдәм итүгә бүлеп бирелгән акчалардан файдалану һәм тиешле дәүләт институтларының эшчәнлеге турында халык алдында хисаплылык;
- халык нәфис промыселларына һәм кәсепләренә, шулай ук әлеге өлкәдә эшкуарлык эшчәнлегенең артель һәм гаилә рәвешләренә ярдәм итү;

• кредит-инвестиция механизмнарын - лизингны, франчайзингны, венчурлы инвестицияләүнең махсуслаштырылган инвестиция институтларын үзләштерүне тизләтү;

• кече предприятиеләрне кредитлау системасын әлеге предприятиеләрнең гамәлгә куючыларының шәхси акчалары белән, ипотека кредитлавы, шулай ук кече эшкуарлыкка ярдәм фонды, яңа кече предприятиеләр белән кооперация бәйләнешләренә кызыксынучы эре предприятиеләр гарантияләре белән тәэмин итеп үстерү;

• нәтиҗәсез һәм түләүгә сәләтсез предприятиеләр мөлкәтен кече эшкуарлыкны ресурс белән тәэмин итү һәм аның инфрастуктура объектларын төзү чыганагы буларак файдалану;

• теләсә кайсы эшкуар файдаланырлык законнар, салымнар, конкурентлар, клиентлар, базар торышы турында эшлекле белешмәләре булган мәгълүмат челтәре булдыру;

• икътисадның кече эшкуарлык секторы торышын, аның үсеш тенденцияләрен объектив бәяләү, кече эшкуарлыкка дәүләт ярдәмен корректировкалау буенча тәкъдимнәр әзерләү максатында кече эшкуарлык проблемалары буенча системалы тикшеренүләр оештыру;

• кече эшкуарлыкны исәпкә алу һәм дәүләт статистикасы системасын яхшырту;

• эшкуарларны криминаль структуралар йогынтысыннан яклауны тәэмин итү;

• кече эшкуарлык секторы эшчәнлеген кызыксындыруга, халыкны үз бизнесы белән шөгыльләнүгә әзерләүгә юнәлдерелгән пропагандистлык һәм уку-укыту кампаниясен оештыру, эшкуарларның тармаклар, районнар, һөнәри һәм башка билгеләр буенча берләшүе, эшкуарлар турында тиешле иҗтимагый фикер формалаштыру.

## III. Программа чараларынын структурасы

Программа чаралары структурасы җиде юнәлештән (бүлектән) тора, алар комплекслы алымны һәм ведомствоара кооперацияне тәэмин итә, бер үк вакытта һәр юнәлештә үзенең эчке бурычлары билгеләнә (Программаны гамәлгә ашыруның төп чаралары).

## IV. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү

2004 ел ахырына программа чараларын гамәлгә ашырганнан соң 20 меңнән артык кече предприятиегә дәүләт ярдәме күрсәтелергә тиеш.

Программа чараларын үтәү кысаларында кече эшкуарлык өлкәсендә эш урыннарын 40 меңгә арттыра алырлык гамәлдәге һәм яңа барлыкка килгән кече предприятиеләр һәм юридик зат булып тормаган эшкуарлар өчен шартлар булдыру күздә тотыла.

Программа чаралары төгәлләнгәч кече эшкуарлыкның тулаем эчке продуктка гомуми кертеме 15 процентка кадәр артыр дип карала.

## V. Программа белән идарә итү һәм аны контрольдә тоту механизмы

Программа чараларын гамәлгә ашыруны ведомствоара һәм дәүләтара координацияләү һәм аның барышын контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты башкара.

Кабул ителгән максатчан программа кысаларында үткәрелә торган кече эшкуарлыкка дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыруда башкарма хакимият органнарының җаваплылыгын арттыру максатында әлеге программаларның дәүләт заказчылары чираттагы елга үз бюджет заявкаларында кече эшкуарлыкка ярдәм итүгә Татарстан Республикасы республика бюджетыннан ассигнованиеләрне аерым билгелиләр.

Программа үтәлешенең барышы Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре комиссиясе утырышларында даими карала.

## VI. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

1. Программаны гамәлгә ашыруның төп механизмын программа чараларын үтәүнең еллык планнарын раслау һәм аерым чараларны башкаручылар белән дәүләт контрактлары (шартнамәләре) төзү тәшкил итә. Эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкаручылар конкурс нигезендә билгеләнә. Бу максатларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кызыксынучы министрлыклар, ведомстволар һәм оешмалар белән бергә теге яисә бу тематика буенча конкурслы сайлап алуны үткәрү регламентын эшли.

Программа чаралары кысаларында эш башкаручыларга Татарстан Республикасының республика бюджетыннан акча бүлеп бирү конкурс нигезендә башкарылырга тиеш. Программа чараларын үтәүдә кызыксынучы коммерциячел һәм башка оешмаларның катнашуы әлеге эшләрне финанслауда өлешчә катнашуны күз алдында тотучы кайбер килешүләр, шартнамәләр нигезендә тормышка ашырыла.

2. Татарстан Республикасы районнарының һәм шәһәрләренең хакимият башлыклары әлеге Программага салынган алымнар нигезендә Программа кабул ителгәннән соң бер квартал дәвамында 2001-2004 елларга кече эшкуарлык үсеше буенча үз (район, шәһәр) программаларын әзерлиләр һәм кабул итәләр.

3. Татарстан Республикасының Балалар һәм яшьләр эшләре дәүләт комитеты, Татарстан Республикасының Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт комитеты, Татарстан Республикасының югары уку йортлары ректорлары Советы, яшьләр оешмалары белән берлектә, Яшьләр эшкуарлыгын үстерү буенча ярдәмче программа әзерлиләр, анда исә яшьләргә ярдәм итү турында әлеге Программадагы һәм Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының тиешле карарларындагы алымнардан файдаланалар. Ярдәмче программаның максаты җитештерүне үстерүгә яшьләрне җәлеп итү, яшь гаиләләрнең тормыш дәрәҗәсен күтәрү мөмкинлеге, үзенә уңайлы торак төзүгә реаль мөмкинлек алу, һөнәри дәрәҗәсен күтәрү.

4. Татарстан Республикасының Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт комитеты хатын-кызлар иҗтимагый оешмалары, Татарстан Республикасының социаль тәэмин итү департаменты, Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәга палатасы белән берлектә, хатын-кызлар эшкуарлыгына ярдәм итү буенча ярдәмче программа әзерлиләр, анда Программада каралган шундый ук алымнарны кулланалар. Ярдәмче программаның максаты - эшкуарлык өлкәсенә хатын-кызларны күбрәк тарту, хатын-кызлар өчен яңа эш урыннары булдыру, хатын-кызларны яңа һөнәргә өйрәтү.

5. Татарстан Республикасының Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт комитеты, Татарстан Республикасының Социаль тәэминат министрлыгы, Кече эшкуарлыкка ярдәм һәм аны үстерү департаменты, Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәга палатасы, инвалидларның җәмәгать оешмалары физик мөмкинлекләре чикле кешеләр хезмәтеннән файдаланучы (эшләүчеләрнең 15-20 проценты) җитештерү өлкәсендәге кече предприятиеләргә конкрет ярдәм күрсәтү буенча тәкъдимнәр әзерлиләр.

6. Министрлыклар, ведомстолар һәм оешмалар Программаны гамәлгә ашыру буенча төп чаралар нигезендә күрсәтелгән программа чараларын билгеләнгән вакытларда үтиләр.

## VII. Программаны финанслау

2001 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан ассигнованиеләр 25 млн.сум күләмендә каралган. Моннан тыш, Программа чараларын гамәлгә ашыру өлешчә финанслау шартларында җирле бюджетлар, бюджеттан тыш финанс чыганаклары акчаларын кече эшкуарлык субъектларының үз акчаларын җәлеп итеп башкарылачак.

Әлеге акчаларны җәлеп итү Программаны гамәлгә ашыруда аерым килешүләр, шартнамәләр, контрактлар нигезендә башкарыла. Шуңа бәйле рәвештә Программаны эшләгәндә җәлеп ителгән акчалар күләме алдан планлаштырылмый. Җәлеп ителгән финанс чаралары күләме Программа кысаларында әзерләнгән финанс технологияләрен куллану уңышына бәйле булачак.

Кече бизнес проектында өлешчә инвестицияләүнең потенциаль катнашучылары буларак, Программа белән республика (ведомствоара) башка программаларының дәүләт заказчылары каралган.

Программаны гамәлгә ашыру барышында финанс технологияләре инвестицияләргә бюджеттан тыш ресурсларны җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк, ә кече эшкуарлык субъектларының җитештерү эшчәнлеге инвестицияләрне чагыштырмача кыска вакыт эчендә кире кайтарып кына калмыйча, базарда үз капиталы белән һәм заем акчаларына җайга салынган схемалар буенча керү юлы булган тотрыклы кече бизнес ачарга мөмкинлек бирәчәк.

## 2001-2004 елларга кече эшкуарлыкны үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт комплекслы программасын гамәлгә ашыруның төп чаралары

### 1. Кече эшкуарлык эшчәнлеген норматив хокукый тәэмин итү

| № | Гамәлнең исеме | Документның исеме | Гамәлне үтәүче | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| 1.1. | Кече бизнесны үстерү буенча Россия һәм халыкара тәҗрибәне исәпкә алып, закон проектлары һәм башка норматив хокукый актлар әзерләү: | | | |
| | «Татарстан Республикасында эшкуарлык үсешенә дәүләт ярдәменең гомуми принциплары турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Кече эшкуарлык проблемаларына комплекслы якын килү нигезендә эшкуарлык үсешенә дәүләт ярдәме принциплары | Дәүләт Советы, ТРФА, Икътисад министрлыгы, Фининслар министрлыгы, Юстиция министрлыгы, ЭЯҮД, ССП | 2001 ел II квартал |
| | | | | |
| | «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Теркәү палатасы эшен камилләштерү турында» ТР МК карары | Юридик затларны, ХЭны һәм милекчелек хокукын теркәү вакытын кыскарту, теркәүче органның теркәү вакытын бозган өчен җаваплылыгын билгеләү | Юстиция министрлыгы, Фининслар министрлыгы, ЭЯҮД, Дәүләт мөлкәте комитеты, ССП, Теркәү палатасы | 2001 ел, II квартал |
| | | | | |
| | | «Бер тәрәзә» принцибы буенча теркәүнен универсаль процедурасын кертү | | |
| | | | | |
| | | Теркәү өчен документларның тулы исемлеген билгеләү | | |
| | | | | |
| | | Кече предприятиеләрне теркәү системасын гадиләштерү | | |
| | | | | |
| | «Күчемсез мөлкәт | 1. Тулысынча дәүләт | Дәүләт мөлкәте | 2001 ел |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | объектларын арендага бирүне тәртипкә китерү турында» Министрлар Кабинеты карары | һәм коммуналь милектәге, торак булмаган биналарның эшкуарлар өчен ачык белешмәләр базасын булдыру | комитеты, Икътисад министрлыры, ЭЯҮД, ССП, КМИК | II квартал |
| | | 2. Дәүләт һәм коммуналь милектәге торак булмаган биналарны арендага аукционнар һәм конкурслар аша тапшыру турында нигезләмә эшләү | | |
| | | | | |
| | «Лизинг компанияләре турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | Татарстан Республикасында лизинг проектларын финанслау өчен ассигнованиеләр бүлеп бирү турында | Икътисад министрлыгы, Финанслар министрлыгы, ЭЯҮД, ССП | 2001 ел II квартал |
| | | | | |
| | «Җир бүлеп бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | 1. Җир кишәрлекләрен бүлеп бирү тәртибен гадиләштерү<br>2. Җир кишәрлекләре буенча эшкуарлар өчен ачык белешмәләр базасын булдыру | Икътисад министрлыгы, Дәүләт мөлкәте комитеты, Финанслар министрлыгы, Дәүләт җир комитеты, ЭЯҮД, ССП | 2001 ел II квартал |
| | | | | |
| | «Кече эшкуарлар эшчәнлегенә контрольлек итүне тәртипкә салу турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | 1. Тикшерүләр планын һәм тикшерүнең датасын, максатын, тикшерүченең эш урынын һәм фамилиясен билгеләүче күрсәтмә рәвешләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру | Икътисад министрлыгы, ДСИ, ЭЯҮД, ССП Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләре администрациясе | 2001 ел 15 апрель |
| | | 2. Контроль органнарының компетенцияләрен, вәкаләтләрнең кабатланмавына юл куймыйча, бүлү | | |
| | «Татарстан Республикасының Экология фондына хисап бирү тәртибен һәм күләмен билгеләү | Татарстан Республикасының Экология фондында хисаплылыкның гадиләштерелгән | Икътисад министрлыгы, Финанслар министрлыгы, ЭЯҮД, ССП, ТРның | 2001 ел II квартал |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | турында» ТР МК карары | рәвешләрен кертү | Экология фонды | |
| | | | | |
| | «Эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен йөкләнгән керемгә берләштерелгән салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты | Республикада кече эшкуарлык үсеше өчен уңай шартлар тәэмин итү | ЭЯҮД, ССП | 2001 ел, 15 апрель |
| | | | | |
| | «Торак милекчеләре ширкәтләрен төзү турында» Татарстан Республикасы законы проекты | Торакка дәүләт милкен демонополизацияләү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | 2002 ел |
| | | | | |
| | «Татарстан Республикасының торак фондына хезмәт күрсәтүләрне демонополизацияләү турында» ТР МК карары | Татарстан Республикасы торак фонды белән идарә итү һәм файдалану буенча заказчының һәм подрядчының функцияләрен бүлү, базар мохитен булдыру | ТР МК, ЭЯҮД, ССП | 2002 ел |
| | | | | |
| 1.2. | Кече эшкуарлык субъектлары өчен бердәй социаль салым ставкаларын 20 процентка кадәр үзгәртү турында федераль законнарга тәкъдимнәр әзерләү | | Татарстан Республикасы халык депутатлары, Татарстан Республикасыннан Россия Федерациясе Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы депутатлары | 2001 ел, III квартал |
| | | | | |
| 1.3. | Кече предприятиеләрнең коммуналь хезмәтләр белән гарантияле шартнамәчел мөнәсәбәтләрне рәсмиләштерү буенча Татарстан Республикасы Министрлар | Кече предприятиеләр эшчәнлеген тәэмин итүче оешмалар белән мөнәсәбәтләрне гадиләштерү һәм шулай итеп кече бизнес субъектлары эше һәм үсеше өчен гарантияле уңай шартлар тудыру | ЭЯҮД, ССП | 2001 ел, II квартал |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Кабинетының тиешле карарларына тәкъдимнәр комплексын әзерләү | | | |

## 2. Кече эшкуарлыкка ярдәм итүнең прогрессив финанс технологияләрен үстерү

Әлеге гамәлләрне башкаруга чаралар: эшкуарларның үзләренең акчалары, Татарстан Республикасының республика бюджеты, җирле бюджетлар акчалары, тиешле фондлар акчалары, кредит ресурслары

| № | Гамәлнең исеме | Максаты | Гамәлне үтәүче | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 2.1. | Кече эшкуарлыкны финанслау системасын гарантияләр бирү һәм иминләштерү нигезендә камилләштерү | Кече эшкуарлык субъектларын финанслау системасын кече эшкуарлык өлкәсенә ресурслар җәлеп итү максатларында гарантияләр бирү нигезендә камилләштерү | ТР МК, ССП, РФКЭЯФ, районнарның һәм шәһәрләрнең КЭЯ фондлары, НИОКР фонды, Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды, банклар, иминият компанияләре | 2001-2002 еллар |
| 2.2. | Кече эшкуарлыкта лизинг һәм франчайзинг куллану гамәлен киңәйтү | Кече предприятиеләрне техник җиһазлау | Фондлар, банклар, лизинглар, иминият һәм башка компанияләр | 2001-2004 еллар |
| 2.3. | Кече предприятиеләрне микрокредитлауның, үзара финанслауның, һәм иминләштерүнең механизмнарын һәм структураларын үстерү | Кече предприятиеләр эшчәнлеге өчен уңай һәм тотрыклы финанс шартлары булдыру | Фондлар, банклар, лизинглар, иминият һәм башка компанияләр | 2001-2004 еллар |
| 2.4. | Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме республика фонды эшчәнлеген алга таба үстерү һәм камилләштерү, шул исәптән банклар белән бергә берләшеп | Кече предприятиеләр эшчәнлеге өчен уңай һәм тотрыклы финанс шартлары булдыру | ТР МК | ел саен |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.5. | Товарларны җитештерү өлкәсендә кайтарып бирү шарты белән, вакытлы һәм түләүле нигездә кече эшкуарлык субъектларының проектларын максатчыл финанслау | | ЭЯҮД, фондлар | Ел саен |
| 2.6. | Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме күрсәтүнең әйләнештәге капитал фондларын формалаштыру өчен хосусый инвестицияләрне, банкларның кредит ресурсларын, инвестиция фондлары акчаларын һәм бүтән финанс ресурсларын җәлеп итү механизмын эшләү | Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме күрсәтү фондларының тотрыклы һәм нәтиҗәле эшен тәэмин итү | Финанслар министрлыгы, Икътисад министрлыгы, ЭЯҮД, ССП, Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләре администрацияләре каршындагы кече эшкуарлыкка ярдәм итү буенча комитетлар | Ел саен |
| 2.7. | Кече предприятиеләрдә дәүләт заказын урнаштыруны оештыру ягыннан һәм норматив хокукый яктан тәэмин итүнең механизмын формалаштыру | Кече предприятиеләр өчен тотрыклы эшләр күләмен тәэмин итү, яңа эш урыннары булдыру | Финанслар министрлыгы, Икътисад министрлыгы, ДПРП, ТПП, ТР министрлыклары һәм ведомстволары, ТР районнары һәм шәһәрләре администранияләре | Ел саен |
| 2.8. | Кече предприятиеләр өчен эшчәнлекнен өстенлекле һәм социаль әһәмияткә ия юнәлешләрендә яңа төр продукцияне үзләштерә торган ташламалы кредитларны конкурс нигезендә бирү, кредит буенча процентларны кече эшкуарлыкка ярдәм итү фондлары | Өстенлекле һәм социаль әһәмиятле юнәлешләрдә эшләүче кече предприятиеләр өчен уңай эшчәнлек шартларын тәэмин итү | ТР МК, РФКЭЯФ, фондлар, банклар | Ел саен |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | исәбеннән түләтү | | | |
| 2.9. | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өлкәсендәге фермер хуҗалыкларының проектларын максатчыл кредитлау | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өлкәсендәге кече предприятиеләрнең үсешенә һәм нормаль эшчәнлегенә һәрьяклап ярдәм күрсәтү | ТР МК, фондлар, банклар, ТФА | Ел саен |
| 2.10 | Татарстан Республикасында теркәлгән кече предприятиеләр өчен республикада җитештерелүче чималны сату буенча товар-чимал биржасын оештыру | Чимал базарын демонополизацияләү, мохитнең конкурентлылыгын булдыру | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | 2002 ел |

## 3. Кече эшкуарлыкны үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыру

- өстенлекле өлкәләрдә эшләүче кече предприятиеләр өчен дәүләт заказының конкрет өлешен тәэмин итү;
- кече предприятиеләр эшчәнлегенең башлангыч стадиясендә салым каникулларын куллану;
- файдаланылмаган җитештерү мәйданнарын өстенлекле рәвештә бирү, өстенлекле өлкәләрдә эшләүче кече предприятиеләргә файдаланылмаган җиһазларны тапшыру;
- коммерция банкларын җәлеп итеп, Татарстан Республикасының милли банкы, «Ак Барс» акционер коммерция банкы» ААҖ тарафыннан өстенлекле өлкәләрдә эшләүче кече предприятиеләргә кредит ярдәме күрсәтүне оештыру;
- кече предприятиеләр тарафыннан җитештерүгә һәм хезмәт күрсәтүләрне киңәйтүгә инвестицияләнүче табыштан керемнәрне салымнардан азат итү;
- уйлап табышлардан файдалануны кызыксындыру максатында патентка ия кече предприятиеләргә ташламалар билгеләү.

| № | Гамәлнең исеме | Максаты | Гамәлне үтәүче | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| 3.1. | Агросәнәга комплексы һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү | Фермер хуҗалыкларының санын һәм аларның нәтиҗәлелеген, шул исәптән авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү исәбенә арттыру | ТР МК, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре, ТФА | 2001-2004 еллар |
| | | | | |
| 3.2. | Кече сәнәга җитештерүе һәм экспортка эшләнүче товарларны һәм импортка алыштырылучы товарларны җитештерү, инновацион технологияләр | Җитештерү өлкәсендә эшләүче кече предприятиеләрнең санын арттыру, эре бизнеска фәнни хезмәт күрсәтү | ТР МК, ТР ФА, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре | 2001-2004 еллар |
| | | | | |
| 3.3. | Кече төзелеш индустриясе | Өстенлекле өлкәләрдә эшләүче кече предприятиеләрнең тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итү | ТР МК, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре | 2001-2004 еллар |
| | | | | |
| 3.4. | Энергияне сак тоту, шул исәптән тикшерү приборларын җитештерү һәм гамәлгә кертү, ресурсны саклаучы һәм җылылыкны саклаучы технологияләрне эшләү, альтернатив энергия чыганакларын эшләү һәм кертү | | ТР МК, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре, «Татэнерго» ПЭБ | 2001-2004 еллар |
| | | | | |
| 3.5. | Медицина, шул исәптән: медицина хезмәте күрсәтү, медицина инструментлары һәм приборлары җитештерү, дару үләннәре җитештерү | Халыкка медицина хезмәте күрсәтү сыйфатын арттыру | ТР МК, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре | 2001-2004 еллар |
| | | | | |
| 3.6. | Мәгълүмати сервис: мәгълүмат үзәкләре, интернет пунктлары, мәгълүмат базаларын булдыру | | Икътисад министрлыгы, Финанс министрлыгы, Мәгълүмат һәм | 2001-2004 еллар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | матбугат министрлыгы, Элемтә министрлыгы, ЭЯҮД, ССП | |
| 3.7. | Яшьләрнең кече эшкуарлык эшчәнлеге | Җитештерүне, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне үстерүгә, шул исәптән туризмны үстерүгә яшьләрне җәлеп итү, яшь гаиләләрнең тормыш дәрәҗәсен арттыру мөмкинлеге, шәхси төзекләндерелгән торак төзүгә реаль мөмкинлекләр алу, һөнәри дәрәҗәсен күтәрү | ТР МК, яшьләрнең җәмәгать оешмалары, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре | 2001-2004 еллар |
| 3.8. | Хатын-кызларның кече эшкуарлык эшчәнлеге | Хатын-кызларны күп санда кече эшкуарлыкка җәлеп итү, хатын-кызлар өчен яңа эш урыннары булдыру, хатын-кызларны яңа һөнәргә өйрәтү | ТР МК, Иҗтимагый хатын-кызлар оешмалары, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре | 2001-2004 еллар |
| 3.9. | Физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең хезмәтеннән файдаланучы кече предприятиеләр (эшләүчеләр санынnan 15-20 процент) | Физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне эшкуарлыкка җәлеп итү, инвалидларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү | ТР МК, «Татарстан Республикасы инвалидлары җәмгыяте» Татарстан республика оешмасы, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре | 2001-2004 еллар |
| 3.10. | Торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә кече эшкуарлык | Торак-коммуналь хуҗалыгының конкуренцияле мохитен булдыру, үзкыйммәтен киметү, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын арттыру | ТР МК, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре | 2002-2004 еллар |

## 4. Кече эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасын һәм мәгълүмат системаларын үстерү

| № | Гамәлнең исеме | Максаты | Гамәлне үтәүче | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 4.1. | Республика шәһәрләрендә һәм районнарында, эшкуарларга норматив-белешмә материалларга, мәгълүмат базаларына һәм башкаларга иркле үтеп керү мөмкинлеге биреп, Интернетны да кертеп, җиһазландырылган консультацион-мәгълүмати пунктлар булдыру | Кече эшкуарлыкка ярдәм итүнең инфрастуктурасын комплекслы үстерүне булдыру | ЭЯҮД, ССП, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре | 2001 ел |
| 4.2. | Массакүләм мәгълүмат чараларында кече эшкуарлык субъектларына мәгълүмати ярдәм күрсәтү (Идел буе федераль округы кысаларында) | | Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, ЭЯҮД, Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләре администрацияләре, ММЧның электрон һәм матбугат чаралары | Ел саен |
| 4.3. | Республикада Арадашчы судлар системасын үстерү | Эшкуарларның икътисадый бәхәсләрне хәл итү мөмкинлекләрен киңәйтү | ССП, ССП каршындагы Арадашчы суд | 2001-2004 еллар |
| 4.4. | Башкарма органнар практикасына кече предприятиеләрне үстерү индикаторлары системасын эшләү һәм гамәлгә кертү | | Икътисад министрлыгы, ЭЯҮД, ТР МК каршындагы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге | 2001-2002 еллар |
| 4.5. | Кече эшкуарлыкны | | Икътисад | 2001 ел |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | үстерүдә статистик тикшеренүләрнең мониторгингын тәэмин итү | | министрлыгы, ЭЯҮД, Дәүләт статистика комитеты, ССП, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре | |

## 5. Кече һәм урта эшкуарлыкны фәнни-методик һәм кадрлар белән тәэмин итү

| № | Гамәлнең исеме | Максаты | Гамәлне үтәүче | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 5.1 | Кече эшкуарлык өлкәсе өчен хезмәткәрләр укытуны, аларның белгечләрен күтәрүне һәм яңа һөнәргә өйрәтүне оештыру | Кече бизнеска юнәлдерелгән югары квалификацияле белгечләр классын формалаштыру | Икътисад министрлыгы, ЭЯҮД, ТР югары уку йортлары, ССП, фондлар | 2001-2004 еллар |
| 5.2 | Түбәндәге тәкъдимнәр белән «Эшкуарга ярдәмгә» мәгълүмати брошюралар сериясен әзерләү һәм чыгару:<br>1. Бизнесны оештыру буенча.<br>2. Кече предприятиеләрдә хезмәтне саклауны оештыру буенча | Кече эшкуарлыкның урта звеносы җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең белем дәрәҗәсен күтәрү | Икътисад министрлыгы, ЭЯҮД, Финмин, ССП, ДСИ, ТР ведомстволары, фондлар | 2001-2002 еллар |
| 5.3 | Мәгариф гамәлләрен оештыру: бизнесны планлаштыруга өйрәтү буенча семинарлар, курслар, конференцияләр | Кече предприятиеләрнең бизнес планнары төзү дәрәҗәсен халыкара стандартларга туры китерерлек итеп күтәрү, республикага чит ил инвестицияләрен җәлеп итү | Икътисад министрлыгы, ЭЯҮД, Юстиция министрлыгы, Финмин, ССП | 2001-2002 еллар |

## 6. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү һәм эшкуарлык эшчәнлеген пропагандалау

| № | Гамәлнең исеме | Максаты | Гамәлне үтәүче | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 6.1 | Массакүләм мәгълүмат чаралары аша эшкуарның уңай образын формалаштыру | | Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, ЭЯҮД, ССП, массакүләм мәгълүматның электрон һәм матбугат чаралары | 2001-2004 еллар |
| 6.2 | Кече предприятиеләр продукциясе белән даими эшләүче күргәзмә-ярминкәләр һәм күмәк стендлар оештыру | Республиканың кече предприятиеләре эшчәнлеге нәтиҗәләре белән таныштыру. Базарларга кече предприятиеләрнең товарларын чыгару, эре предприятиеләр белән кооперацияне үстерү | Икътисад министрлыгы, ЭЯҮД, ССП, ТР районнары һәм шәһәрләре администрацияләре, «Казан ярминкәсе» ААҖ | 2001-2004 еллар |
| 6.3 | Татарстан Республикасында һәм Идел буе федераль округында инновацион проектларның даими эшләүче гамәлдәге күргәзмәсен оештыру | | Икътисад министрлыгы, ЭЯҮД, Сәүдә министрлыгы, ССП | Ел саен |

## 7. Кече эшкуарлык өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлек

| № | Гамәлнең исеме | Максаты | Гамәлне үтәүче | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 7.1 | Кече эшкуарлык субъектларының халыкара конференцияләрдә, семинарларда, күргәзмә-ярминкәләрдә тәҗрибә уртаклашу программаларында катнашуларын тәэмин итү | Кече предприятиеләрнең продукциясен сату базарын, тәҗрибәләр уртаклашуны киңәйтү, кече бизнеска инвестицияләр җәлеп итү | ЭЯҮД, Сәүдә министрлыгы, ТР физкультура, спорт һәм туризм дәүләт комитеты, ТБД, ССП | 2001-2004 еллар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7.2 | Халыкара программалар кысаларында гамәлләрне уздыру (махсус план буенча) | | ТР МК, ССП | 2001-2004 еллар |
| 7.3 | Татарстан Республикасында чит ил фирмаларының җиһазлар, товарлар һәм продукцияләр ярминкәләрен, күргәзмәләрен оештыру | Чит ил партнерлары белән багланышларны киңәйтү | Сәүдә министрлыгы, ЭЯҮД, ССП | 2001-2004 еллар |
| 7.4 | Төбәкара конференцияләрнең эшлекле миссияләрен, контракт биржаларын Идел буе федераль округы дәрәҗәсендә оештыру һәм уздыру | Идел буе федераль округы чикләрендә кече предприятиеләрнең кооперациясен үстерү | ЭЯҮД, ТБД, ССП | 2001-2004 еллар |

## Таблицаларда файдаланылучы кыскартылмалар

**ТР** - Татарстан Республикасы;

**ТР МК** - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

**Дәүләт Советы** - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы;

**ТР ФА** - Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе;

**Дәүләт мөлкәте комитеты** - Татарстан Республикасының Дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт комитеты;

**Сәүдә министрлыгы** - Татарстан Республикасының Сәүдә һәм икътисадый хезмәттәшлек министрлыгы;

**Икътисад министрлыгы** - Татарстан Республикасының Икътисад һәм сәнәга министрлыгы;

**Финмин** - Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы;

**Юстиция министрлыгы** - Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы;

**Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы** - Татарстан Республикасының Матбугат, телерадиотапшырулар эшләре һәм массакүләм коммуникацицияләр чаралары министрлыгы

**Элемтә министрлыгы** - Татарстан Республикасы Элемтә министрлыгы;

**ТР ФТДК** - Татарстан Республикасының Физик культура, спорт һәм туризм буенча дәүләт комитеты;

**Дәүләт жир комитеты** - Татарстан Республикасының Җир ресурслары һәм жир реформасы буенча дәүләт комитеты;

**Дәүләт статкомитеты** - Татарстан Республикасының Статистика буенча дәүләт комитеты;

**КМИК** - Казан шәһәре администрациясе каршындагы коммуналь мөлкәткә идарә итү комитеты;

**«ТР инвалидлар җәмгыяте» БИҖнең Татарстан республика оешмасы** - «Татарстан Республикасының инвалидлар җәмгыяте» - «Бөтенроссия инвалидлар җәмгыяте»нең Татарстан республика оешмасы» иҗтимагый оешмасы;

**ЭЯҮД** - Татарстан Республикасы Икътисад һәм сәнәга министрлыгы каршындагы Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү департаменты;

**ССП** - Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәга палатасы;

**РФ КЭЯФ**- Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме күрсәтүнең республика фонды;

**ТФА** - Татарстан фермерларының һәм крестьян хуҗалыкларының ассоциациясе;

**ММЧ** - Массакүләм мәгълүмат чаралары;

**ХЭ** - хосусый эшкуар;

**ДСИ** - Россия Федерациясе Салымнар һәм җыемнар министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

**ТБД** - Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының Тышкы багланышлар департаменты;

**Теркәү палатасы** - Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы теркәү палатасы;

**ТР районнарының һәм шәһәрләренең КЭЯФ** - Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләре администрацияләре каршындагы кече эшкуарлыкка ярдәм итү фонды

**НИОКР** фонды - гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык эшләренең республика фонды

**ТН һәм К** - төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре

3 прог-гали.doc